КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 18 июнь г.Казань № 476

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 317 нче карарына үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 317 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 29 декабрь, 660 нчы; 2006 ел, 19 июнь, 312 нче; 2010 ел, 31 май, 419 нчы; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 26 октябрь, 890 нчы; 2011 ел, 23 декабрь, 1060 нчы; 2012 ел, 2 июнь, 466 нчы; 2012 ел, 10 октябрь, 846 нчы; 2013 ел, 19 март, 185 нче; 2013 ел, 4 декабрь, 955 нче; 2013 ел, 11 декабрь, 974 нче; 2014 ел, 4 июнь, 376 нчы; 2016 ел, 19 март, 150 нче; 2016 ел, 29 октябрь, 796 нчы; 2017 ел, 3 февраль, 58 нче; 2017 ел, 20 апрель, 232 нче; 2017 ел, 18 декабрь, 1008 нче; 2018 ел, 22 март, 161 нче; 2018 ел, 5 июнь, 430 нчы; 2018 ел, 17 декабрь, 1155 нче; 2019 ел, 16 март, 185 нче; 2019 ел, 22 июль, 613 нче; 2020 ел, 11 февраль, 99 нчы; 2020 ел, 21 апрель, 312 нче; 2020 ел, 11 июль, 575 нче; 2020 ел, 19 август, 710 нчы, 2021 ел, 21 гыйнвар, 19 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«2. Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы аппараты буенча хезмәткәрләрнең иң чик санын 2021 елның 1 апреленнән вазыйфаи окладлар буенча хезмәт өчен түләүнең айлык фонды 1 909,365 мең сум күләмендә 85 берәмлек күләмендә билгеләргә.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы турында нигезләмәнең 3.3 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«административ хокук бозулар турында эшләр башкаруны тәэмин итү чараларын куллану һәм аларны саклау кысаларында кулга алынган транспорт чараларын махсуслаштырылган урынга күчерү һәм аларны саклау буенча буенча, шулай ук Татарстан Республикасының административ хокук бозулар турындагы эшләр буенча җәмәгать судьялары, балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре тарафыннан салына торган штрафлар буенча Татарстан Республикасы бюджеты керемнәре администраторының бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыра;

Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының $20.6^{1}$ статьясында каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзи.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы структурасын яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

әлеге карарның 1 пунктындагы алтынчы абзацының гамәле 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

әлеге карарның 1 пунктының алтынчы абзацы 2021 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына законнар нигезендә әлеге карарның 1 пунктын гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган оештыру карарларын кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2005 ел, 6 июль, 317 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 18 июнь, 476 нчы
карары редакциясендә)

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы структурасы

